СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 10-39 от «30» июня 2020 ел

«Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале турында

Гражданнарны хезмәт эшчәнлегендәге тырышлыклары һәм уңышлары, фидакарь иҗади хезмәтләре, җитештерү нормаларын арттырып үтәү, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, продукциянең сыйфатын яхшырту, техниканы нәтиҗәле куллану һәм заманча технологияләрне үзләштерү, кыйммәтле уйлап табулар һәм рационализаторлык тәкъдимнәре, фән, мәдәният, әдәбият, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәүдә, җәмәгать туклануы, торак-коммуналь хуҗалык, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендәге уңышлары, яшьләрне тәрбияләү буенча уңышлы муниципаль һәм иҗтимагый эшчәнлек, физик культура, спорт һәм башка өлкәләрдәге уңышлары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы үсешенә юнәлдерелгән эшчәнлекнең физик культура, спорт һәм башка өлкәләрендәге уңышлары, социаль хезмәт һәм иҗтимагый активлык өлкәсендәге уңышлары өчен бүләкләү, иҗади хезмәтне һәм активлыкны стимуллаштыру максатларында, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы

к а р а р к а б у л и т т е:

1.«Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медален гамәлгә куярга.

2.«Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале турындагы нигезләмәне расларга ( карарга теркәлеп килә).

3.Мамадыш муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә массакүләм мәгълүмат чараларында «Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале белән бүләкләү белән бәйле эшләрне яктыртуны йөкләргә.

4.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында(pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А. П. Иванов

000033

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының 2020 елның 30
июнь № 10-39 карарына
кушымта

«Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале турында

**НИГЕЗЛӘМӘ**

«Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү гражданнарны хезмәт эшчәнлегендәге тырышлыклары һәм уңышлары, фидакарь иҗади хезмәтләре, җитештерү нормаларын арттырып үтәү, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, продукция сыйфатын яхшырту, техниканы нәтиҗәле куллану һәм заманча технологияләрне үзләштерү, кыйммәтле уйлап табулар һәм рационализаторлык тәкъдимнәре, фән, мәдәният, әдәбият, сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәүдә, җәмәгать туклануы, торак - коммуналь хуҗалык, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендәге уңышлары, яшьләрне тәрбияләү буенча нәтиҗәле эшләүләре, муниципаль һәм иҗтимагый эшчәнлек, физик культура, спорт һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районын үстерүгә, Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең үсешенә һәм чәчәк атуына, Татарстан Республикасында һәм Россия Федерациясендә аның ролен һәм әһәмиятен арттыруга зур өлеш керткән, иҗтимагый тормышта иҗади хезмәт һәм активлыкны стимуллаштыруга юнәлдерелгән.

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. «Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале (алга таба - медаль) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бүләге булып тора.

1.2. Медаль белән бүләкләнү хезмәт эшчәнлегендәге тырышлыклары һәм уңышлары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең икътисадый, социаль-мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен танылу билгесе булып тора.

1.3. Медаль белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче гражданнар, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләре гражданнары һәм чит ил гражданнары бүләкләнә.

1.4. Медаль белән бүләкләү турындагы карар Мамадыш муниципаль районы башлыгы тарафыннан кабул ителә. Медаль белән бүләкләү турындагы карар массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында басылып чыга.

1.5. Бүләкләү эшләрен алдан карау, бүләкләү турында бәяләмәләр чыгару буенча эшне оештыру Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бүләкләре һәм мактаулы исемнәре белән бүләкләү өчен тапшырыла торган материалларны карау комиссиясенә (алга таба - Комиссия) йөкләнә, ул муниципаль район башлыгы карары белән раслана.

1.6. Медальләргә Заказ бирү һәм исәпкә алу Мамадыш муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы урынбасары тарафыннан алып барыла.

## II. МЕДАЛЬ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Бүләкләү турындагы мәсьәләне карау өчен медаль белән бүләкләнүгә тәкъдим ителүченең конкрет казанышларын күрсәтеп, бүләкләүгә тәкъдим итү турында үтенечнамә рәсмиләштерелә.

2.2. Медаль белән бүләкләү турындагы үтенечнамәне кертергә түбәндәгеләр хокуклы:

а) милек рәвешенә һәм кайсы ведомствога каравына карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хезмәт коллективлары;

б) иҗтимагый оешмалар.

Гражданнарның шәхси мөрәҗәгатьләре буенча бүләкләү үткәрелми.

2.3. Аерым очракларда медаль белән бүләкләүгә тәкъдим итү Мамадыш муниципаль районы башлыгы инициативасы белән дә башкарыла.

2.4. Иҗтимагый оешмалар, хезмәт коллективлары Мамадыш муниципаль районы башлыгы исеменә тәкъдим кертә, алдан хезмәт коллективларында яки иҗтимагый оешмаларда, аларның коллегиаль органнарында кандидатуралар турында фикер алыша.

2.5. Бүләкләү инициаторы расланган форма буенча (1 нче кушымта) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге башлыгы исеменә гариза һәм бүләкләү кәгазе тапшыра.

2.6. Комиссия:

а) медаль белән бүләкләү өчен документларны алдан карый, документларның комплектлылыгын һәм әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килүен тикшерә;

б) Мамадыш муниципаль районы Башлыгының медаль белән бүләкләү турындагы карарлары проектларын әзерли.

## III. МЕДАЛЬ ТАСВИРЛАМАСЫ

3.1. Медаль һәм аңа таныклыклар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан раслана (2 нче һәм 3 нче кушымталар).

## IV. МЕДАЛЬ ТАПШЫРУ ТӘРТИБЕ

4.1. Медаль тантаналы шартларда Мамадыш муниципаль районы башлыгы тарафыннан шәхсән тапшырыла.

4.2. Медаль белән бүләкләнүче үлгән очракта, щгщр ул исщщн вакытта тапшырылмаган булса, бүләк бүләкләнүченең гаиләсенә тапшырыла.

4.3. Медаль белән бүләкләнгән затлар аның сакланышына сакчыл карарга тиеш. Медаль югалган очракта дубликат бирелми.

4.4. Медаль күкрәкнең сул ягында йөри һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка медальләре булганда алардан соң урнаша.

## V. БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА КАРАРЛАРНЫ ГАМӘЛДӘН ЧЫГАРУ, МЕДАЛЬДӘН МӘХРҮМ ИТҮ

5.1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгы бүләкләү турындагы карарны, бүләкләгәннән соң медаль белән бүләкләнүнең дөрес булмавы яки нигезсезлеге ачыкланса, гамәлдән чыгарырга хокуклы.

5.2. Бүләкләүне гамәлдән чыгару турында Карар кабул ителгән затка тапшырылган медаль Мамадыш муниципаль районы Советы аппаратына кире кайтарылырга тиеш.

5.3. Медальдән мәхрүм итү бары тик Мамадыш муниципаль районы Башлыгы тарафыннан, аеруча авыр яки авыр җинаять кылган өчен хөкем ителгән очракта - законлы көченә кергән суд карары нигезендә генә башкарылырга мөмкин.

“Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге медальләре турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**БҮЛӘКЛӘҮ КӘГАЗЕ**

Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале белән бүләкләү.

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме:
татар телендә
рус телендә
2. Вазыйфасы эш, хезмәт урыны (цехның,бүлекнең, предприятиенең, оешманың, учреждениенең, министрлыкның, дәүләт комитетының, җирле үзидарә органының, ведомствоның төгәл атамасын күрсәтергә):
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
3. Җенесе ________________________ 4. Туган көне һәм урыны________________________
____________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
5. Милләте ________________________ 6. Белеме ______________________
________________________________________________________________________
(уку йорты исемен , белгечлеген күрсәтергә)

________________________________________________________________________
7. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме, махсус исеме:_________________________
________________________________________________________________________
8. Нинди дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән , бүләкләү датасы: _______________
________________________________________________________________________
9. Бүләкләүнең башка төрләре: _____________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
10. Яшәү урыны, адресын күрсәтеп:
_______________________________________________________________
________________________________________________________________________
11. алдагы эш урыннары:

| "_____" ____ | "_ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ _ | Вазыйфасы, эш урыны, урнашу урыны учреждениесе, оешмалар |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

12. Гомуми эш стажы: ____________ Тармактагы эш стажы:________________________
Әлеге хезмәт коллективында эш стажы: _____________________________________
13. Конкрет хезмәт күрсәтүләрен күрсәтеп, бүләкләүгә тапшырыла торган Характеристика

14. ___________________________________ кандидатурасы җыелыш, хезмәт коллективы Советы тарафыннан тәкъдим ителде

____________________________________________________

______________________________________________________________________________

предприятие, берләшмәләр, учреждениеләр, оешмалар исеме,

______________________________________________________________________________

фикер алышу датасы, беркетмә N

Кандидатура буенча фикер алышуда катнаштылар _____________ кеше
Тавыш бирделәр: "_______" Риза" "Каршы" _________ "икеләнде" _________

М. У. Предприятие, учреждение, оешма җитәкчесе,

_____________________________

Профсоюз комитеты рәисе ______________________

хезмәт коллективы Советы (җыелыш) рәисе

_____________________________________

“Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы” муниципаль
берәмлеге медальләре турындагы
Нигезләмәгә2 нче кушымта

«Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале
ТАСВИРЛАМАСЫ

«Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале нейзильбердан диаметры 32 мм, калынлыгы 3 мм көмеш төстәге түгәрәк формасында. Медальнең сул ягында район производствосының башлыча авыл хуҗалыгы юнәлешен күрсәтүче өч башакның рельефлы сурәте һәм күтәрү краны сүрәте урнашкан. Уң якта - районда урнашкан җитештерүләрнең экологик яктан чиста булуын күрсәтүче һәм районда эшләүче урман хуҗалыкларын күрсәтүче символ - китап, һәм сәнәгать объектының символик сурәтләре, яфрак рәсеме куелган. Үзәк буенча аскы өлешендә - Мамадыш сүзе язылган рельеф тасма сүрәте. Сулдан уңга медаль әйләнәсе буенча - Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд - дигән сүзләр язылган рельефлы язу.

Медаль колакчык һәм божра ярдәмендә 24 мм киңлектәге муар тасма белән уратып алынган биш очлы колодка белән, анда Мамадыш муниципаль районы флагының өч төсе: 11 мм яшел, 4 мм киңлектәге ак һәм 9 мм киңлектәге зәңгәр төсле тасмалар, тоташтырыла. Арткы ягында медальне киемгә беркетү өчен булавка куелган.


ФИДАКАРЬ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН - ЗА ДОБЛЕСТНЫЙ ТРУД
МАМАДЫШ

**МАМАДЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# УДОСТОВЕРЕНИЕ

**К МЕДАЛИ «ФИДАКАРЬ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН - ЗА ДОБЛЕСТНЫЙ ТРУД»**



“Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге медальләре турындагы Нигезләмәгә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы

ТАНЫКЛЫК № ____

______________________________

_______________________________________________________

_________________________________________________________

**Мамадыш муниципаль районы башлыгының __________2020 ел, №___ карары нигезендә «Фидакарь хезмәт өчен - За доблестный труд» медале белән бүләкләнә**

**Район башлыгы ________________ _____________**

**МУ** **имза**